**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**26 ноябрь 2021 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн өлкәннәрдэн 150 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүг буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Зур Сукаеш авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү);
- Тракторчыга карны механикалаштырылган җыю хезмәте өчен түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре);
- Зур Сукаеш авылы территорияләрен төзекләндерү (территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);
- Зур Сукаеш авылы зиратын киртәләп алу өчен материаллар сатып алу, зират коймаларын әзерләү һәм урнаштыру, лак-буяу материалы алу, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», Халыкара өлкәннәр көнен” бүләк һәм сувенир продукция сатып алу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сукаеш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында тбәндәге адрес буенча: Зур Сукаеш авылы, Совет ур., 30 йорт, һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге башлыгы Закирова З.Җ.